# САБИТОВА И.И. ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЬЯСАЛЫШ СҮЗЛЕГЕ: «КЕШЕ» ТЕМАТИК ТӨРКЕМЕНӘ КАРАГАН ЛЕКСИКА

«Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: “кеше” тематик төркеменә караган лексика» басмасы «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителде. Аны төзүче автор – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова. Җаваплы редакторлары филология фәннәре докторлары, профессор Ф.Ә. Ганиев һәм профессор К.Р. Галиуллин.

Сүзьясалышы сүзлекләренең төп үзенчәлеге сүз ясалуның юлларын билгеләүдән, ясаучы һәм ясалма сүзләр арасында үзара бәйләнешләрне ачыклаудан гыйбарәт. Сүзьясалышы сүзлекләрендә нинди дә булса бер ирекле тамыр (яки ирекле нигез) астына бөтен тамырдаш сүзләрне җыю белән бергә аларның үзара бәйләнешләрен күрсәтү дә мөһим шарт. Мондый басмалар сүзләрнең сүзьясалыш потенциалын һәм структурасын төгәлрәк билгеләү өчен дә хезмәт итәләр. Тәкъдим ителгән сүзлек хәзерге лексикографиядә кабул ителгән принципларга җавап бирерлек дәрәҗәдә һәм сүзьясалыш сүзлекләренә куела торган таләпләрне искә алып эшләнгән. Автор әлеге кулланмасын күренекле дериватолог А.Н.Тихоновның сүзьясалыш оялары принципларына нигезләп төзелгән һәм белгечләр тарафыннан югары бәяләнгән «Словообразовательный словарь русского языка» (2 томда), К.Г. Ишбаев һәм З.К. Ишкилдина төзегән башкорт теленең кыскача сүзьясалыш сүзлеге үрнәгендә әзерләгән.

Татар тел белемендә сүзьясалыш сүзлекләренә караган ике белешмәлек билгеле. Беренчесе – А.М. Ямалетдинова һәм И.А. Латыйпова тарафыннан «Кеше. Кеше тәне (организмы) өлешләре» дигән тематик төркем материаллары буенча төзелгән «Русча-татарча тематик сүзьясалышы сүзлеге» – Башкортстанның Туймазы шәһәрендә 2007 елда дөнья күрә. Икенчесе – шул ук елда Ф.С. Сафиуллина, З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Йосыпова һәм И.Г. Мифтахова тарафыннан әзерләнгән «Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге» – Казан федераль университеты нәшриятында басылып чыга. И.И. Сабитова хезмәтендә исә аларның да уңай яклары чагылыш тапкан. Нәтиҗәдә телебездәге «Кеше» тематик төркеменә караган лексик берәмлекләр сүзьясалыш ояларына туплап бирелгән, бу тематик төркемгә кергән сүзләрнең сүзьясалыш потенциалы шактый тулы һәм ачык күрсәтелгән, ояларга кергән ясалма сүзләрнең сүзьясалыш структурасы дөрес итеп билгеләнгән сүзлек барлыкка килгән.

Ирексездән, ни өчен төзүче шушы тематик төркем лексикасына мөрәҗәгать иткән соң?

дигән сорау туа. Моның җавабы бик гади. Кешенең тән әгъзаларын белдерә торган сүзләр – соматизмнар телнең иң борынгы катламына карый. Алар үзләренең телдә булган үзгәрешләргә аз бирелүчән булулары, даимилекләре, сүзьясалыш потенциалы югарылыгы белән аерылып тора һәм лексиканың иң тотрыклы тармагын тәшкил итә. Бу сүзләр күпсанлы, күпмәгънәле һәм көнкүрештә, аралашуда еш кулланыла, татар теленең төп лексик фондын хасил итәләр. Шуңа күрә дә авторның әлеге тематик төркем өчен сүзьясалыш сүзлеген төзүне максат итеп алуы гаҗәпләндерми.

Тәкъдим ителә торган әлеге сүзлек ике бүлектән тора. Сүзьясагыч ояларны тәшкил иткән төп бүлектән соң, ояларга урнаштырылган ясалма сүзләрнең алфавит тәртибендәге исемлеге дә бирелгән. Һәрбер ясалма сүз янында ул урнашкан ояның нумерациясенә туры килгән индекс та күрсәтелгән.

Сүзлек өчен материал күптөрле чыганаклардан – татар теленең төрле типтагы сүзлекләреннән, анатомия буенча дәреслек-кулланмалардан җыелган. Сүзлектә барлыгы 3325 сүз туплап бирелгән. Шуларның 3147 се ясалма сүз һәм алар үзләренең сүзьясалыш бәйләнешләрен саклаган 178 ояга урнаштырылган.

Татар телендә сүзьясагыч кушымчалар, гадәттә, нигез сүзне үзгәртмичә, аңа турыдан-туры ялганып, яңа сүзләр ясыйлар. Сүзлектә кайсы сүзьясалыш нигезенә нинди сүзьясагыч чаралар кулланып, нинди сүзләр ясалуы күрсәтелгән. Нигез сүзләрнең сүзьясалыш оялары эчендә деривацион таралышы һәм мөмкинлекләре дә ачыкланган. Ояга кергән ясалма сүзләрнең зур өлешен кушымчалау ысулы белән ясалган синтетик сүзләр тәшкил иткән. Мәсәлән:

**МЫЕК** *и. анат.*
  мыек-**лач** *и. зоол.*
  мыек-**лы** *с.*
  мыек-**сыз** *с.*
  мыек-**ча** *и.*
    мыекча-**лы** *с.*
    мыекча-**сыз** *с.*
      мыекчасыз-**лар** *и. күпл. зоол.*
  мыек-**чан** *с.*
...

Кушымчалаудан тыш, ояларда күпсанлы кушма сүзләр, шул исәптән парлы сүзләр дә урын алган: *эч-бавыр, эч-баш, эч-карын, эчәк-бавыр, йөз-кыяфәт* һ.б. Бу ояларда компонентлары кушылып язылган кушма сүзләр дә күп: *икейөзле, керфеккорсаклылар, йөззурлык, үрдәкборын, озынборын, каратүш, тәнкисәр* һ.б.

**АЯК I** *и. анат.* Әгъза
  ...
  аяк-кул *җый. и. к.* **кул**
  ...
  аяг/үрә *рәв.* [к//г]
  аяк/чу *җый. и.*
  аяк бит-*е и. к.* **бит**
  ...
  баш-аяк *җый. и. к.* **баш**
  алтын/сыман каз/аяк *и. бот.*
  баш/аяк *рәв. гади с. к.* **баш**
  ...
  агу-**лы** каз/аяк *и. бот.*
  ...

Татар телендә сүзьясалыш системасының тагын бер үзенчәлеге – аналитик конструкцияләрнең

күп булуы. Бу үзенчәлек «кеше» дигән тематик төркемгә караган сүзләрдән ясалган ояларда да чагылган: *бит алмасы, борын канаты, борын яфрагы* һ.б. Шул ук вакытта бу төркем кысаларында биология, медицина өлкәләренә караган күпсанлы терминнар да (*дагаборынлылар, үрдәкборын, йомшактәнлеләр, карга борыны, тәнкисәр, кызылтүш, күкрәк куышлыгы* һ.б.) байтак ясалган.

Сүзлекнең күләме 8,7 автор табагы һәм ул 600 данә тираж белән басылып чыккан. Сүзлек киң катлау укучыларга, мәктәп укытучыларына, студентлар, аспирантлар, галимнәргә тәкъдим ителә.

«Кеше» тематик төркеменә караган лексиканың сүзьясалышы сүзлеге – татар телендә аерым бер тематик төркем кысаларында төзелгән беренче хезмәт. Эзлекле фәнни принципларга таянып, җентекләп тикшерелгән, өйрәнелгән һәм сүзлеккә теркәлгән бай тел материалы телебезнең, борынгы чорлардан алып, хәзерге көнгә кадәрге үсешен, таралышын күзалларга ярдәм итә, һәм татар теленең искиткеч зур сүзьясалыш потенциалына ия икәнен тагын бер кат исбатлый.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*